**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О молодежи и государственной молодежной политике в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 апреля 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 19 октября 1993 года № 1983-XII «О молодежи и государственной молодежной политике в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 26 мая 2005 года № 73-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 10; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I часть); 2013, № 4 (I часть); 2014, № 1 – 2; 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I); 2018, № 54 (часть I) изменения, изложив его в следующей редакции:

«ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О молодежной политике в Республике Татарстан**

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 30 декабря 2020 года № 489-ФЗ «О молодежной политике в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон), другими федеральными законами регулирует отдельные вопросы в сфере молодежной политики в Республике Татарстан, отнесенные к полномочиям органов государственной власти субъектов Российской Федерации.

Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 3. **Цели молодежной политики в Республике Татарстан**

Целями молодежной политики в Республике Татарстан являются:

1) защита прав и законных интересов молодежи;

2) обеспечение равных условий для духовного, культурного, интеллектуального, психического, профессионального, социального и физического развития и самореализации молодежи;

3) создание условий для участия молодежи в политической, социально-экономической, научной, спортивной и культурной жизни общества;

4) повышение уровня межнационального (межэтнического) и межконфессионального согласия в молодежной среде;

5) формирование системы нравственных и смысловых ориентиров, позволяющих противостоять идеологии экстремизма, национализма, проявлениям ксенофобии, коррупции, дискриминации по признакам социальной, религиозной, расовой, национальной принадлежности и другим негативным социальным явлениям;

6) формирование культуры семейных отношений, поддержка молодых семей, способствующие улучшению демографической ситуации в Республике Татарстан.

Статья 4. **Принципы молодежной политики в Республике Татарстан**

Молодежная политика в Республике Татарстан основывается на принципах:

1) сочетания интересов личности, общества и государства, обеспечения сбалансированности интересов и прав молодежи, молодых семей, молодежных общественных объединений и интересов и прав иных граждан, общественных объединений и организаций;

2) взаимодействия федеральных органов государственной власти, органов государственной власти Республики Татарстан и иных субъектов Российской Федерации, органов местного самоуправления, осуществляющих деятельность в сфере молодежной политики;

3) комплексного, научного и стратегического подходов при формировании и реализации молодежной политики;

4) открытости и равного доступа молодежи, молодых семей, молодежных общественных объединений к соответствующим мерам государственной поддержки;

5) приоритетности государственной поддержки социально незащищенных молодых граждан, молодых семей;

6) обязательности участия молодежи, молодых семей, молодежных общественных объединений в формировании и реализации молодежной политики.

Статья 5. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере молодежной политики**

К полномочиям органов государственной власти Республики Татарстан в сфере молодежной политики относятся:

1) реализация молодежной политики на территории Республики Татарстан, в том числе разработка и осуществление мер, мероприятий, способствующих реализации основных направлений молодежной политики;

2) разработка и реализация республиканских и межмуниципальных программ по основным направлениям в сфере молодежной политики с учетом социально-экономических, экологических, демографических, этнокультурных и других особенностей Республики Татарстан, в том числе направленных на воспитание морально-нравственных ценностей, формирование у молодежи интереса и уважения к традициям, обычаям и культуре татарского народа и народов, проживающих на территории Республики Татарстан;

3) организация деятельности специалистов по работе с молодежью;

4) организация и осуществление мониторинга реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан;

5) создание и развитие инфраструктуры молодежной политики;

6) формирование и реализация механизмов поддержки молодежных инициатив;

7) поддержка и развитие различных форм воспитательной работы в молодежных и детских общественных объединениях, организациях, осуществляющих образовательную деятельность;

8) создание условий для оздоровления и отдыха молодежи;

9) экологическое просвещение и вовлечение молодежи в мероприятия по защите природы, сохранению и улучшению состояния окружающей среды;

10) создание условий для психолого-педагогической помощи и социальной адаптации молодых граждан;

11) иные полномочия в сфере молодежной политики, отнесенные в соответствии с Федеральным законом, другими федеральными законами, законами Республики Татарстан к полномочиям органов государственной власти Республики Татарстан.

Статья 6. **Полномочия органов местного самоуправления в сфере молодежной политики**

К полномочиям органов местного самоуправления в сфере молодежной политики относятся:

1) участие в реализации молодежной политики;

2) разработка и реализация мер по обеспечению и защите прав и законных интересов молодежи на территории муниципального образования;

3) организация и проведение мероприятий по работе с молодежью на территории муниципального образования;

4) разработка и реализация муниципальных программ по основным направлениям реализации молодежной политики;

5) организация и осуществление мониторинга реализации молодежной политики на территории муниципального образования;

6) иные полномочия в сфере реализации прав молодежи, определенные федеральными законами.

Статья 7. **Реализация молодежной политики в Республике Татарстан**

1. В соответствии с Федеральным законом основными направлениями реализации молодежной политики в Республике Татарстан являются:

1) воспитание гражданственности, патриотизма, преемственности традиций, уважения к отечественной истории, историческим, национальным и иным традициям народов Российской Федерации;

2) обеспечение межнационального (межэтнического) и межконфессионального согласия в молодежной среде, профилактика и предупреждение проявлений экстремизма в деятельности молодежных объединений;

3) поддержка молодых граждан, оказавшихся в трудной жизненной ситуации, инвалидов из числа молодых граждан, а также лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей;

4) поддержка инициатив молодежи;

5) содействие общественной деятельности, направленной на поддержку молодежи;

6) организация досуга, отдыха, оздоровления молодежи, формирование условий для занятий физической культурой, спортом, содействие здоровому образу жизни молодежи;

7) предоставление социальных услуг молодежи;

8) содействие решению жилищных проблем молодежи, молодых семей;

9) поддержка молодых семей;

10) содействие образованию молодежи, научной, научно-технической деятельности молодежи;

11) организация подготовки специалистов по работе с молодежью;

12) выявление, сопровождение и поддержка молодежи, проявившей одаренность;

13) развитие института наставничества;

14) обеспечение гарантий в сфере труда и занятости молодежи, содействие трудоустройству молодых граждан, в том числе посредством студенческих отрядов, профессиональному развитию молодых специалистов;

15) поддержка и содействие предпринимательской деятельности молодежи;

16) поддержка деятельности молодежных общественных объединений;

17) содействие участию молодежи в добровольческой (волонтерской) деятельности;

18) содействие международному и межрегиональному сотрудничеству в сфере молодежной политики;

19) предупреждение правонарушений и антиобщественных действий молодежи;

20) поддержка деятельности по созданию и распространению, в том числе в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», в средствах массовой информации произведений науки, искусства, литературы и других произведений, направленных на укрепление гражданской идентичности и духовно-нравственных ценностей молодежи;

21) проведение научно-аналитических исследований по вопросам молодежной политики.

2. Молодежь участвует в реализации молодежной политики в формах, предусмотренных Федеральным законом.

Статья 8. **Государственная поддержка молодежных и детских общественных объединений, инициатив молодежи**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан оказывают молодежным и детским общественным объединениям поддержку в соответствии с Федеральным законом от 28 июня 1995 года № 98-ФЗ «О государственной поддержке молодежных и детских общественных объединений» и настоящим Законом.

2. Государственная поддержка в соответствии с настоящим Законом может оказываться зарегистрированным в установленном законодательством Российской Федерации порядке:

1) межрегиональным, республиканским и местным молодежным общественным объединениям граждан в возрасте до 35 лет включительно, объединившихся на основе общности интересов;

2) межрегиональным, республиканским и местным детским общественным объединениям граждан в возрасте до 18 лет и совершеннолетних граждан, объединившихся для осуществления совместной деятельности.

3. Государственная поддержка молодежных и детских общественных объединений оказывается при соблюдении следующих условий:

1) объединение является юридическим лицом и действует на территории Республики Татарстан не менее одного года с момента его государственной регистрации;

2) объединение осуществляет свою деятельность на постоянной основе.

4. Соответствие обращающегося за государственной поддержкой молодежного или детского общественного объединения установленным настоящим Законом требованиям определяется органом исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющим государственное управление в сфере молодежной политики в Республике Татарстан (далее – орган исполнительной власти в сфере молодежной политики).

5. Объединение молодежного или детского общественного объединения в ассоциацию (союз) с другими молодежными или детскими общественными объединениями при сохранении им организационной самостоятельности не может

служить основанием для исключения его из числа объектов государственной поддержки.

6. Поддержка общественно значимых инициатив молодежи, молодежных и детских общественных объединений в Республике Татарстан включает:

1) осуществление мер по поддержке общественных инициатив молодых граждан и молодежных общественных объединений по созданию условий для реализации созидательной активности, потенциала молодых граждан и добровольческой (волонтерской) деятельности во всех сферах общественной жизни;

2) совершенствование информационного и научно-методического обеспечения деятельности молодежных и детских общественных объединений;

3) привлечение молодежи к консультативной деятельности органов государственной власти Республики Татарстан в области молодежной политики, распространение практики создания и деятельности консультативных органов по проблемам молодежи;

4) привлечение молодежных и детских общественных объединений к обсуждению проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам осуществления прав и законных интересов молодежи.

### Статья 9. **Республиканский реестр молодежных и детских общественных объединений, пользующихся государственной поддержкой**

1. Орган исполнительной власти в сфере молодежной политики формирует и ведет Республиканский реестр молодежных и детских общественных объединений, пользующихся государственной поддержкой (далее – Республиканский реестр). Порядок ведения Республиканского реестра определяется органом исполнительной власти в сфере молодежной политики.

2. Включение молодежных и детских общественных объединений в Республиканский реестр осуществляется бесплатно в течение 30 дней после представления ими письменного заявления и документов, подтверждающих соответствие молодежного или детского общественного объединения требованиям части 3 статьи 8 настоящего Закона.

3. Молодежные и детские общественные объединения, включенные в Республиканский реестр, один раз в год представляют в орган исполнительной власти в сфере молодежной политики документы, подтверждающие соответствие молодежного или детского общественного объединения требованиям части 3 статьи 8 настоящего Закона.

4. В Республиканский реестр включаются следующие сведения о молодежном или детском общественном объединении:

1) полное и (если имеется) сокращенное наименования, адрес (место нахождения) его постоянно действующего руководящего органа;

2) государственный регистрационный номер записи о государственной регистрации (основной государственный регистрационный номер);

3) идентификационный номер налогоплательщика;

4) код причины постановки на учет;

5) регистрационный номер в Пенсионном фонде Российской Федерации;

6) цель создания и деятельности молодежного или детского общественного объединения в соответствии с его уставом;

7) информация о видах деятельности, осуществляемых молодежным или детским общественным объединением;

8) дата включения его в Республиканский реестр;

9) дата и основание его исключения из Республиканского реестра.

5. Молодежное или детское общественное объединение, включенное в Республиканский реестр, может быть исключено из указанного Реестра на основании:

1) письменного заявления молодежного или детского общественного объединения;

2) непредставления в установленный срок молодежным или детским общественным объединением, включенным в Республиканский реестр, один раз в год в орган исполнительной власти в сфере молодежной политики документов, подтверждающих соответствие молодежного или детского общественного объединения требованиям части 3 статьи 8 настоящего Закона;

3) включения молодежного или детского общественного объединения в реестр некоммерческих организаций, выполняющих функции иностранного агента.

6. Орган исполнительной власти в сфере молодежной политики в течение пяти рабочих дней со дня принятия решения об исключении молодежного или детского общественного объединения из Республиканского реестра уведомляет в письменной форме такое объединение о принятом решении.

7. Информация, содержащаяся в Республиканском реестре, является общедоступной и предоставляется в соответствии с Федеральным законом от 9 февраля 2009 года № 8-ФЗ «Об обеспечении доступа к информации о деятельности государственных органов и органов местного самоуправления».

8. Орган исполнительной власти в сфере молодежной политики ежеквартально представляет в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по оказанию государственных услуг и управлению государственным имуществом в сфере государственной молодежной политики, указанные в пунктах 1 – 7 части 4 настоящей статьи сведения о молодежных и детских общественных объединениях, включенных в Республиканский реестр.

### Статья 10. **Международное сотрудничество в сфере молодежной политики**

1. Международное сотрудничество в сфере молодежной политики осуществляется в соответствии с законодательством Российской Федерации, международными договорами Российской Федерации.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан, иные государственные органы Республики Татарстан, органы местного самоуправления осуществляют взаимодействие в сфере молодежной политики с международными организациями, иностранными государственными органами, а также иностранными неправительственными организациями в пределах своей компетенции в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, в следующих формах:

1) разработка и реализация программ и проектов в сфере молодежной политики;

2) поддержание международных связей и содействие обеспечению представительства интересов молодых граждан Российской Федерации в международных и межгосударственных организациях по вопросам международного сотрудничества, международных молодежных обменов;

3) обмен опытом в сфере молодежной политики;

4) иные формы, предусмотренные законодательством Российской Федерации.

Статья 11. **Координация деятельности в сфере молодежной политики в Республике Татарстан**

Координацию деятельности в сфере молодежной политики в Республике Татарстан осуществляет орган исполнительной власти в сфере молодежной политики в соответствии с положением, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 12. **Информационное и научное обеспечение реализации молодежной политики в Республике Татарстан**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления и организации, подведомственные субъектам, осуществляющим деятельность в сфере молодежной политики, обеспечивают открытость и доступность информации о реализации молодежной политики.

2. Информация о реализации молодежной политики включает в себя данные официального статистического учета, касающиеся реализации молодежной политики, данные мониторинга реализации молодежной политики и иные данные, получаемые при осуществлении своих функций органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, а также организациями, осуществляющими деятельность в сфере молодежной политики. Информационное обеспечение реализации молодежной политики осуществляется в том числе посредством федеральной государственной автоматизированной информационной системы.

3. Органы государственной власти Республики Татарстан:

1) информируют молодых граждан, молодежные и детские общественные объединения об их правах и обязанностях, о проводимых мероприятиях, затрагивающих интересы молодежи, о ходе реализации молодежной политики в Республике Татарстан, в том числе через средства массовой информации и информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет»;

2) обеспечивают проведение научных разработок в сфере молодежной политики и социологических исследований о положении молодежи.

Статья 13. **Мониторинг реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан**

1. Мониторинг реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан представляет собой систематическую, комплексную и плановую деятельность по сбору, обобщению, анализу и оценке информации о положении молодежи, молодых семей и молодежных общественных объединений в Республике Татарстан, об обеспечении межнационального (межэтнического) и межконфессионального согласия в молодежной среде, о предотвращении формирования экстремистских молодежных объединений и иных проявлений идеологии экстремизма, национализма в целях подготовки доклада о положении молодежи в Республике Татарстан (далее – доклад).

2. Организация мониторинга реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан и подготовка доклада осуществляются органом исполнительной власти в сфере молодежной политики.

3. Кабинет Министров Республики Татарстан ежегодно не позднее чем через три месяца по окончании календарного года направляет доклад Президенту Республики Татарстан, а также представляет доклад Государственному Совету Республики Татарстан.

4. Доклад доводится до сведения органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, других субъектов, осуществляющих деятельность в сфере молодежной политики в Республике Татарстан, и подлежит размещению на официальном сайте органа исполнительной власти в сфере молодежной политики.

Статья 14. **Консультативные, совещательные и иные органы**

1. При органах государственной власти Республики Татарстан и органах местного самоуправления могут создаваться консультативные, совещательные и иные органы из числа представителей молодежных и детских общественных объединений, научных, образовательных и иных организаций и лиц, специализирующихся на изучении проблем молодежи и практической работе среди молодежи.

2. Полномочия, порядок формирования и деятельности консультативных, совещательных и иных органов, их персональный состав утверждаются органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления, при которых они созданы.

Статья 15. **Финансовое обеспечение реализации молодежной политики в Республике Татарстан**

Финансовое обеспечение реализации молодежной политики в Республике Татарстан осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан в пределах средств, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и плановый период

на указанные цели, а также иных источников, не запрещенных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. В целях реализации настоящего Закона понятие «государственная молодежная политика» в нормативных правовых актах Республики Татарстан, изданных до принятия настоящего Закона, используется в том же значении, что и понятие «молодежная политика», установленное Федеральным законом от 30 декабря 2020 года № 489-ФЗ «О молодежной политике в Российской Федерации».

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
05 мая 2021 года
№ 35-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 1 – 2; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

### 3 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең максатлары**

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

2) яшьләрне рухи, мәдәни, интеллектуаль, психик, һөнәри, социаль һәм физик яктан үстерү һәм аларга үз-үзен таныту өчен тигез шартлар тәэмин итү;

3) яшьләрнең җәмгыятьнең сәяси, социаль-икътисадый, фәнни, спорт һәм мәдәни тормышында катнашуы өчен шартлар тудыру;

4) яшьләр арасында милләтара (этносара) һәм конфессияара татулык дәрәҗәсен күтәрү;

5) экстремизм, милләтчелек идеологиясенә, ксенофобия, коррупция чагылышларына, социаль, дини, раса, милли сыйфатлар буенча дискриминациягә һәм башка тискәре социаль күренешләргә каршы торырга мөмкинлек бирә торган әхлакый һәм мәгънәви ориентирлар системасын булдыру;

6) Татарстан Республикасында демографик хәлне яхшыртуга булыша торган гаилә мөнәсәбәтләре культурасын булдыру, яшь гаиләләргә ярдәм итү.

### 4 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең принциплары**

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) шәхес, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренең ярашуы, яшьләр, яшь гаиләләр, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре мәнфәгатьләренең һәм хокукларының һәм башка гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар мәнфәгатьләренең һәм хокукларының балансба булуын тәэмин итү;

2) яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлекне башкара торган федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге;

3) яшьләр сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда комплекслы, фәнни һәм стратегик алымнар;

4) тиешле дәүләт ярдәме чараларының ачыклыгы һәм яшьләрнең, яшь гаиләләрнең, яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең бу чаралардан тигез файдалана алу мөмкинлеге;

5) социаль якланмаган яшь гражданнарга, яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме өстенлеге;

6) яшьләрнең, яшь гаиләләрнең, яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең яшьләр сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу мәҗбүрилеге.

### 5 статья. **Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, шул исәптән яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыруга ярдәм итә торган гамәлләрне, чараларны эшләү һәм башкару;

2) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып яшьләр сәясәте өлкәсендә төп юнәлешләр буенча, шул исәптән мораль-әхлакый кыйммәтләрне тәрбияләүгә, яшьләрдә татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә кызыксыну һәм ихтирам булдыруга юнәлдерелгән республика программаларын һәм муниципальара программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

3) яшьләр белән эшләүче белгечләрнең эшчәнлеген оештыру;

4) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм башкару;

5) яшьләр сәясәте инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

6) яшьләр инициативаларына ярдәм итү механизмнарын булдыру һәм гамәлгә ашыру;

7) яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрендә, мәгариф эшчәнлеген башкара торган оешмаларда тәрбия эшенең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү;

8) яшьләрне сәламәтләндерү һәм аларның ялы өчен шартлар тудыру;

9) яшьләрне экологик агарту һәм табигатьне яклау, әйләнә-тирә мохит торышын саклау һәм яхшырту чараларына җәлеп итү;

10) яшь гражданнарга психологик-педагогик ярдәм һәм социаль җайлашу өчен шартлар тудыру;

11) яшьләр сәясәте өлкәсендә Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләр.

6 статья. **Яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

3) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм уздыру;

4) яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

5) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм башкару;

6) яшьләр хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә федераль законнарда билгеләнгән башка вәкаләтләр.

7 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру**

1. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданлык, патриотизм, традицияләрнең дәвамчанлыгын, ватан тарихына, Россия Федерациясе халыкларының тарихи, милли һәм башка традицияләренә ихтирам тәрбияләү;

2) яшьләр арасында милләтара (этносара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, яшьләр берләшмәләре эшчәнлегендә экстремизм чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү;

3) авыр тормыш хәлендә калган яшь гражданнарга, инвалид яшь гражданнарга, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга ярдәм итү;

4) яшьләр инициативаларына ярдәм итү;

5) яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү;

6) яшьләрнең буш вакытын, ялын, аларны сәламәтләндерүне оештыру, яшьләрнең физик культура, спорт белән шөгыльләнүе өчен шартлар тудыру, сәламәт яшәү рәвешенә булышлык күрсәтү;

7) яшьләргә социаль хезмәтләр күрсәтү;

8) яшьләрнең, яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтү;

9) яшь гаиләләргә ярдәм итү;

10) яшьләргә белем бирүгә, яшьләрнең фәнни, фәнни-техник эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;

11) яшьләр белән эшләүче белгечләр әзерләүне оештыру;

12) сәләтле яшьләрне ачыклау, аларга теләктәшлек һәм ярдәм күрсәтү;

13) остазлык институтын үстерү;

14) яшьләрнең хезмәте һәм аларны эш белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләрне тәэмин итү, яшь гражданнарны эшкә урнаштыруга, шул исәптән студентлар отрядлары аша, яшь белгечләрнең һөнәри үсешенә булышлык күрсәтү;

15) яшьләрнең эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү һәм булышлык күрсәтү;

16) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

17) яшьләрнең ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуына булышлык күрсәтү;

18) яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлеккә булышлык күрсәтү;

19) яшьләрнең хокук бозуларын һәм җәмәгатьчелеккә каршы гамәлләрен кисәтү;

20) яшьләрнең гражданлык тәңгәллеген һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен ныгытуга юнәлдерелгән фән, сәнгать, әдәбият һәм башка әсәрләрне булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, тарату эшчәнлегенә ярдәм итү;

21) яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча фәнни-аналитик тикшеренүләр үткәрү.

2. Яшьләр Федераль законда каралган рәвешләрдә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша.

8 статья. **Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә, яшьләр инициативаларына дәүләт ярдәме**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә «Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме турында» 1995 елның 28 июнендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон һәм әлеге Закон нигезендә ярдәм күрсәтәләр.

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән түбәндәгеләргә әлеге Закон нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтелергә мөмкин:

1) мәнфәгатьләр уртаклыгы нигезендә берләшкән 35 яшькә кадәрге (бу яшьне дә кертеп) гражданнарның төбәкара, республика һәм җирле яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә;

2) уртак эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен берләшкән 18 яшькә кадәрге гражданнарның һәм балигъ булган гражданнарның төбәкара, республика һәм җирле балалар иҗтимагый берләшмәләренә.

3. Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме түбәндәге шартлар үтәлгәндә күрсәтелә:

1) берләшмә юридик зат булып торса һәм дәүләт теркәве үткән вакыттан кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә эшләсә;

2) берләшмә үз эшчәнлеген даими нигездә башкарса.

4. Дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы) тарафыннан билгеләнә.

5. Яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең, оештыру ягыннан мөстәкыйльлеген саклаган килеш, яшьләрнең яисә балаларның башка иҗтимагый берләшмәләре белән ассоциациягә (берлеккә) берләшүе аны дәүләт ярдәме объектлары исемлегеннән төшереп калдыру өчен нигез була алмый.

6. Татарстан Республикасында яшьләрнең, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларына ярдәм итү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) иҗтимагый яшәешнең барлык өлкәләрендә яшь гражданнарның иҗади активлыгын, потенциалын һәм ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча яшь гражданнарның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең иҗтимагый инициативаларына ярдәм чараларын башкару;

2) яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлеген мәгълүмати һәм фәнни-методик тәэмин итүне камилләштерү;

3) яшьләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының яшьләр сәясәте өлкәсендәге консультатив эшчәнлегенә җәлеп итү, яшьләр

проблемалары буенча консультатив органнар булдыру һәм аларның эшчәнлеге практикасын тарату;

4) яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын тикшерүгә җәлеп итү.

9 статья. **Дәүләт ярдәменнән файдалана торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестры**

1. Яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы Дәүләт ярдәменнән файдалана торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын (алга таба – Республика реестры) булдыра һәм алып бара. Республика реестрын алып бару тәртибе яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

2. Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен Республика реестрына кертү алар язмача гариза һәм яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законның 8 статьясындагы 3 өлеше таләпләренә туры килүен раслый торган документларны тапшырганнан соң 30 көн эчендә түләүсез башкарыла.

3. Республика реестрына кертелгән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре елга бер тапкыр яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органына яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законның 8 статьясындагы 3 өлеше таләпләренә туры килүен раслый торган документлар тапшыралар.

4. Республика реестрына яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе турында түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) тулы һәм (әгәр булса) кыскартылган исеме, даими эшли торган җитәкче органының адресы (урнашкан урыны);

2) дәүләт теркәве турындагы язуның дәүләт теркәве номеры (төп дәүләт теркәве номеры);

3) салым түләүченең идентификация номеры;

4) исәпкә куелу сәбәбе коды;

5) Россия Федерациясе Пенсия фондында теркәү номеры;

6) яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсен төзүнең һәм аның эшчәнлегенең устав нигезендәге максаты;

7) яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе башкара торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат;

8) аны Республика реестрына кертү датасы;

9) аны Республика реестрыннан төшереп калдыру датасы һәм нигезе.

5. Республика реестрына кертелгән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе күрсәтелгән Реестрдан түбәндәге нигездә чыгарылырга мөмкин:

1) яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең язмача гаризасы;

2) Республика реестрына кертелгән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе тарафыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органына елга бер тапкыр тиешле срокта яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең

әлеге Законның 8 статьясындагы 3 өлеше таләпләренә туры килүен раслый торган документлар тапшырмау;

3) яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсен чит ил агенты функцияләрен башкара торган коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертү.

6. Яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсен Республика реестрыннан чыгару турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы кабул ителгән карар турында мондый берләшмәгә язмача хәбәр итә.

7. Республика реестрындагы мәгълүмат һәркем өчен ачык була һәм «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелә.

8. Яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы федераль башкарма хакимиятнең дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү функцияләрен башкаручы органына Республика реестрына кертелгән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре турында квартал саен әлеге статьяның 4 өлешендәге 1 – 7 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра.

10 статья. **Яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек**

1. Яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкара килешүләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары халыкара оешмалар, чит ил дәүләт органнары, шулай ук чит ил хөкүмәтнеке булмаган оешмалар белән яшьләр сәясәте өлкәсендә үзара хезмәттәшлекне үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыралар:

1) яшьләр сәясәте өлкәсендә программалар һәм проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) халыкара элемтәләргә ярдәм итү һәм халыкара һәм дәүләтара оешмаларда халыкара хезмәттәшлек, халыкара яшьләр алмашулары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе яшь гражданнарының мәнфәгатьләрен белдерүне тәэмин итүгә булышлык күрсәтү;

3) яшьләр сәясәте өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу;

4) Россия Федерациясе законнарында каралган башка рәвешләр.

11 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү**

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләүне яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

12 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмати һәм фәнни тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы субъектларга караган оешмалар яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру турында мәгълүматның ачыклыгын һәм аны һәркемнең алу мөмкинлеген тәэмин итәләр.

2. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру турында мәгълүмат яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы рәсми статистик исәпкә алу белешмәләрен, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау белешмәләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар тарафыннан үз функцияләрен башкарганда алына торган башка белешмәләрне үз эченә ала. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү шул исәптән федераль дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша башкарыла.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары:

1) яшь гражданнарга, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә аларның хокуклары һәм бурычлары турында, яшьләр мәнфәгатьләренә кагылышлы уздырыла торган чаралар турында, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның барышы турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, мәгълүмат бирәләр;

2) яшьләр сәясәте өлкәсендә фәнни эшләнмәләр һәм яшьләр хәле турында социологик тикшеренүләр уздыруны тәэмин итәләр.

13 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау**

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау Татарстан Республикасында яшьләр хәле турында доклад (алга таба – доклад) әзерләү максатларында Татарстан Республикасында яшьләр, яшь гаиләләр һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең хәле турында, яшьләр арасында милләтара (этносара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү турында, экстремист яшьләр берләшмәләрен формалаштыруга һәм экстремизм, милләтчелек идеологиясенең башка күренешләренә юл куймау турында мәгълүмат җыю, аны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлектән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм доклад әзерләү яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен, календарь ел тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, докладны Татарстан

Республикасы Президентына җибәрә, шулай ук докладны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыра.

4. Доклад Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы башка субъектлар игътибарына җиткерелә һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

14 статья. **Консультатив, киңәшмә һәм башка органнар**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары каршында яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең, фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләреннән һәм яшьләр проблемаларын өйрәнүдә һәм яшьләр арасында практик эш алып баруда махсуслашучы затлардан консультатив, киңәшмә һәм башка органнар төзелергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары каршында төзелгән консультатив, киңәшмә һәм башка органнарның вәкаләтләре, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе, персональ составы аларны төзегән әлеге органнар тарафыннан раслана.

15 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү**

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында шушы максатлар өчен каралган акчалар чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законны гамәлгә ашыру максатларында әлеге Закон кабул ителгәнче бастырылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларындагы «дәүләт яшьләр сәясәте» төшенчәсе «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән «яшьләр сәясәте» төшенчәсе мәгънәсендә кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 05 май
№ 35-ТРЗ